Отыш уйнаучыларга уен вакытында.
Аракы эчеп утыручыларга.
Гайбәт сөйләп торган кешеләргә.
Бәдрәфтә булган кешегә.

Ислам дине буенча иелеп-бөгелеп сәламләшү дөрес түгел, чөнки без бары тик Аллаһы Тәгалә каршында гына иелергә тиешбез. Мөхәммәд галәйһиссәләм болай дигән: *«Бер-берегез белән сәламләшкәндә бөгелмәгез».*

Сәлам барча сүзләрдән дә әүвәл килер. Мөхәммәд галәйһиссәләм бер хәдисендә болай дигән: *"Сәлам сүздән әүвәлдер".*

*("Татар дини календаре»ннан)*

# Камил кеше бар!

**(Мөхәммәд галәйһиссәлләм турында)**

Безнең эраның алтынчы гасырында бу дөньяга бөтен кешелек өчен үрнәк камил кеше җибәрелә – соңгы Пәйгамбәр Мөхәммәд галәйһиссәләм. Бөек Аллаһы изге Коръәндә җирдәге һәм ахирәттәге тормыш бәхетле булсын өчен, барлык кешеләргә Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләмгә иярергә куша.

Кеше туганнан ук төрле хәлләрдә үрнәккә мохтаҗ. Тел, дин, гадәт, фикер, гамәл – барысы да шәхесне формалаштыра. Кеше боларны тирәяктан үзенә сеңдереп бара. Тәрбия һәм белем алуга гаилә, мәктәп һәм, гомумән, җәмгыятьнең уңай һәм тискәре үрнәкләре тәэсир итә.

Кешенең рухи тәрбиясенә, иң беренче чиратта, көчле рухлы шәхесләр йогынты ясый. Кешенең энергияле кешеләргә иярүе – табигый хәл, шуңа күрә көчле шәхес уңай яки тискәре үрнәк күрсәтсә дә, янына үзенә иярүчеләрне җыя. Моңа мисал итеп хәзерге «поп-йолдызлар индустриясе»н күрсәтергә була. Алар кешеләрнең игътибарын үзләренә җәлеп итү белән шөгыльләнә, үз кесәләрен калынайту өчен, аларның аңын һәм җанын ялупа ала.

Кеше тормышы үрнәк, идеал, камиллек һәм яшәеш мәгънәсен эзләүдә үтә. Кешенең җаны куркү, хәвеф һәм билгесезлектән азат булырга тырыша, яктылыкка омтыла, тынычлык һәм бәхет тели. Мөстәкыйль рәвештә мәшәкатьле тормышта иярергә мөмкин булган, ышанычлы үрнәк табу – бик авыр эш, кайгылардан һәм үкенүләрдән котылу мөмкин түгел. Язучы, философ, психологлар дөньяга кеше яратырлык нинди генә фикер бүләк итсәләр дә, кешенең рухи сусавын тулысынча баса алмыйлар. Шуңа күрә кеше нинди генә дәвердә яшәмәсен, дингә, Аллаһыга мөрәҗәгать итә. Бөек Раббыбыз аны кабул итә, догаларына җавап бирә, төрле сынаулардан үткәрә. Җан Аллаһыга мөрәҗәгать итеп, тынычлык һәм куаныч таба.

Бөек Аллаһы кешеләргә тормышта туры юнәлеш табарга ярдәм итә. Аллаһы Тәгалә кешеләргә изге Китаплар һәм кануннарны ачып бирүче пәйгамбәрләр җибәрде. Пәйгамбәрләр – кешеләрнең тәрбиячеләре, алар тугры, гадел, тәкъва булмаган кешеләр җәмгыятенә җибәрелделәр.

Бөек Аллаһы пәйгамбәрләренә махсус сыйфатлар бирә: «садыйк» – бирелгән сүзгә тугрылык, пәйгамбәрләр беркайчан да ялганламый; «әманәт» – ышанычлык, пәйгамбәрләргә төрле эшләрдә таянырга була, алар җаваплы һәм аларга ышаналар; «фатыйнәт» – пәйгамбәрләр иң акыллы кешеләр; «гыйсмәт» – пәйгамбәрләр кечкенә һәм зур гөнаһлар кылмый, ләкин алар кеше булганлыктан, алар тарафыннан зур булмаган хаталар эшләнә, ул гамәлләрне башка кешеләр кылмас өчен, Аллаһы Тәгалә ул хаталарны төзәтә. «Тәблигъ» – Аллаһы Тәгаләнең сүзләрен кешеләргә җиткерү, алар Аллаһының сүзләрен яшермиләр һәм үзләреннән бер сүз дә өстәмиләр. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм һәркемгә үрнәк!

Мөхәммәд галәйһиссәләм, пәйгамбәрләр имамы буларак, барлык пәйгамбәрләрнең иң матур сыйфатларын үзендә туплаган. Ул мул сулы елгалар койган диңгез кебек. Һәрбер кеше аның тормышын үзенә үрнәк итеп алырга мөмкин. Мөхәммәд галәйһиссәләм үзенең бер хәдисендә: *«Мин күркәм әхлакны камилләштерү өчен җибәрелдем»,* – дип әйткән (Әхмәд). Аллаһы Раббыбыз да Коръән-Кәримендә Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләмне мактап: *«Хакыйкатьтә, син – югары әхлак иясе»,* – дигән («Каләм» сүрәсе, 4нче аять).

Ул игелекле, итагатьле, шәфкатьле, миһербанлы, сабыр, киң күңелле, юмарт, ышанычлы, тыйнак була. Бу сыйфатлар Пәйгамбәребез галәйһиссәләмдә иң камил дәрәҗәдә була. Коръәндә әйтелгән: *«Тәхкыйк, Аллаһы Рәсүлендә сезгә иярергә тиешле булган күркәм холык вә яхшы сыйфатлар бардыр, Аллаһыдан савапны һәм ахирәттә җәннәтне өмет иткән хәлдә, Аллаһыны күп зекер итүче мөэминнәр өчен»* («Әхзаб» сүрәсе, 21нче аять).

Аллаһы илчесе галәйһиссәләмнең әхлак чыганагы Коръән булган. Шуңа күрә: «Рәсүлебезнең холкы нинди иде соң?» – дигән сорауга Гайшә анабыз (Аллаһы аннан разый булса иде): «Аның холкы – Коръән иде», – дип җавап биргән. Ул Коръән-Кәрим тыйган нәрсәгә ачуланып караган һәм Коръән-Кәрим кушкан нәрсәдән канәгатьләнү тойган. Ул Аллаһыга ошамаган гамәл кылучыларны хөкем иткән һәм шелтәләгән. Рәсүлебез галәйһиссәләм Аллаһы риза булмаган нәрсәләр өчен генә ачуланган.

Мөхтәрәм мөселманнар! Аллаһы Рәсүле галәйһиссәләм югары дәрәҗәдә намуслы һәм ышанычлы, кешеләр белән мөнәсәбәттә йомшак һәм дустанә кеше булган. Ул әхлакый, саф фикер йөртергә яраткан. Аллаһы Илчесе галәйһиссәләмгә тупаслык, әдәпсезлек һәм оятсызлык ят булган. Ул беркайчан да явызлыкка явызлык белән җавап бирмәгән, дошманнарын кичерә белгән. Әгәр кемдер аннан берәр нәрсә сораса, яки берәр нәрсә белән кызыксынса, Аллаһы Илчесе галәйһиссәләм һәрвакыт йомшак һәм төпле итеп җавап биргән, тупас һәм ихтирамсыз бер сүз дә кулланмаган. Ул беркайчан да әңгәмәдәшен ярты сүздә



*«Гамәлләр бу айда галәмнәрнең Раббысы бөек Аллаһыга фарыз ителер (тартылыр). Мин дә гамәлләремдә уразада буларак Аллаһыга кавышырга теләрмен»,* – дип җавап биргән.

Сөекле Пәйгамбәребез (с.г.в.) хәдисшәрифендә:

«Шәгъбан аеның унбишенче кичәсен гыйбадәт белән үткәрегез, көндезләрендә ураза тотыгыз. Чөнки Раббыбыз Аллаһы бу кичәдә дөнья күкләренә рәхмәте белән карар да: *«Тәүбә иткән юкмы? Аны гафу итәрмен. Ризык теләгән юкмы? Аңа ризык бирермен. Хасталанып шифа теләгән юкмы? Аңа шифа бирермен. Юкмы шуны теләгән, юкмы моны теләгән?»* – дияр. *«Бу халәт иртәнгә кадәр дәвам итәр»,* – дип боерды.

Мөхтәрәм мөселманнар! Бөек Раббыбызның рәхмәтендә, хәер вә бәрәкәтендә, гафу вә мәгъфирәтендә яңгыр кебек өсләребезгә яуган бу мөбарәк кичәнең форсатын белеп, тәүбә, дога һәм ниятялварулар белән үткәрү, бу илаһи зиафәттән (сыйлану тантанасы) файдалану өчен кулыбыздан килгән гайрәтне күрсәтик.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) Аллаһыга ширек кылу, үч һәм дошманлык саклау, тәкәбберлек һәм горурлык эчендә булу, эчке һәм исерткеч куллану, туганнар һәм күршеләр белән араны өзү, ата-ананың хакларын хөрмәт итмәү кебек гөнаһлардан арыну өчен, бу кичәне сәбәп итәрәк тереклек кылуыбызны нәсыйхәт иткән.

Бер-беребезгә сөю вә хөрмәт күрсәтик. Гомумән, яхшылыкка юнәлик.

**Мөхәммәт ГАЛЛӘМ.**
*(«Тугры юл» китабыннан)*

***20 ИЮЛЬДӘ УРАЗА АЕ БАШЛАНА***

# Рамазан — көтелгән бәйрәм

Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына, әҗерсавапларга ирешүдә тиңе һәм чиге булмаган Рамазан ае башлануга бер ай калды — 20 июльдә уразага керәчәкбез. Халкыбызда бу айны олы бәйрәм көткән кебек көтеп алу элек-электән матур гадәткә әверелгән. Тәмле ризык запасларын алдан әзерләп куеп, сәхәрдә тәмле ризыклар ашау, кичләрен туганнар, якыннар, мөселман кардәшләр белән бергәләп авыз ачу, ифтар мәҗлесләре үткәрү арадагы туганлык хисләрен тагын да көчәйткән, мөселманнарны бер-берсенә якынайткан.

Изге Рамазан аенда зур, мәшәкатьле эшләрне куеп торып, күбрәк изгелек кылырга, Коръән укып, нәфел гыйбадәтләре үтәп, шушы бәрәкәтле айның мәгънәви нәтиҗәләренә ирешергә омтылу һәрбер мөселман өчен зарури. Сөекле Пәйгамбәребез үзенең хәдисләрендә Рамазанга алдан әзерләнергә, бу айны көтеп алырга, бу айда изге гамәлләрне күбрәк кылу, аның тулы савапларына ирешү өчен, күп догалар кылып, Аллаһы Тәгаләдән сорарга кушкан.

Ел әйләнәсенә кылган гөнаһларыбызга күп тәүбәләр кылып, рухыбызны чистартып, изге айны көтеп алыйк, Рамазанның олы әҗерләренә ирешү өчен күп догалар кылыйк.

**Ураза фарыз кылынды**

Ислам динендә Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә мөэмин-мөселманнар өчен фарыз иткән, ягъни мотлак рәвештә үтәлергә тиешле булган гамәлләр бар. Аллаһының барлыгына һәм берлегенә бөтен күңеле белән ышанган кеше «Лә иләһә илләллаһ Мухәммәдүр-рәсүлуллаһ» (Аллаһыдан башка илаһ – табыныр зат юк, Мөхәммәд - Аның Пәйгамбәре) дип, теле белән әйтеп иман китерә, бу – беренче фарыздыр. Икенче фарыз гамәл – тәүлегенә биш тапкыр намаз уку. Өченчесе – еллык керемнең кырыктан бер өлешен ярлыларга, мескеннәргә, ятимнәргә, башка тиешле кешеләргә зәкят итеп түләү. Дүртенчесе – Рамазан аенда ураза тоту. Бишенче фарыз гамәл – байлыгы җиткән мөселманнар Мәккә-и Мөкәррәмә шәһәренә хаҗ кылырга тиеш.

Үзен мөселман дип таныган кеше шушы биш фарыз гамәлне җиренә җиткереп үтәргә бурычлы. Рамазан аенда ураза тотуны бөек Раббыбыз Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмгә Мәккәдән Мәдинә шәһәренә һиҗрәт кылганның икенче елында фарыз итте. Бу хакта Шәгъбан аеның башында аятьләр иңдерелде. Менә ул аятьләр: *«Әй, мөэминнәр! Сездән әүвәлгеләргә ураза тоту фарыз ителгән кебек, сезгә дә һәр елны бер ай ураза тоту фарыз ителде, шаять, сез тәкъвалардан булырсыз. Ураза саналмыш көннәрдер, сезләрдән берәрегез чирләсә яки сәфәрдә булса, уразаны тотмасын. Чирле кеше сәламәтләнгәч, сәфәрдәге кеше өенә кайткач, калган көннәрен бер көн өчен бер көн тотып тәмам итәр. Авырлык белән тотучыларга фидия лазем – бер көн өчен бер мескенне ашату. Берәү бер мескен урынына күбрәк мескенне ашатса, артыгы үзенә хәерле. Әмма мескеннәрне ашатып өстегездән төшерүгә караганда, ураза тотуыгыз сезнең өчен хәерлерәк. Рамазан ае бик шәриф ай, ул айда Аллаһыдан кешеләргә туры юлны күрсәтүче һәм һидаятьне ачык бәян кылучы Коръән иңдерелде. Сезләрдән Рамазан аена ирешкән һәрберегез, әлбәттә, ураза тотсын! Аллаһы сезгә җиңеллек тели, авырлык теләми һәм Рамазан уразасын тутырып тотуыгызны һәм Аллаһы сезне туры юлга күндергәне өчен Аны зурлавыгызны тели, шаять, Аллаһыга шөкер итәрсез!»* («Әл-Бәкара» сүрәсе, 184-185нче аятьләр).

№ 26 (1153), 23 июнь 2012 ел
Бердәмлек 7